РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

« 11 » мая 2021 с. Тюлячи № 190

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 541 номерлы «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 541 номерлы «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль Программасын раслау турында» карарына (алга таба - Программа) кушымтаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «09» декабрендәге
541 номерлы карарына кушымта

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль Программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | - «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329 номерлы Федераль закон;<br>- «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 08 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- «Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны |

| | |
|---|---|
| | үстерү концепциясе (төп юнәлешләре) турында» 2001 елның 5 маендагы 256 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br>- «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары |
| Төп максат | - гражданнарның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда физик культура һәм спортның ролен арттыру, гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру;<br>- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;<br>- халыкта, бигрәк тә балалар һәм яшьләрдә, даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвешенә кызыксыну формалаштыру;<br>- яшьләрне физкультура-спорт эшчәнлегенә җәлеп итү хисабына халык арасында авырулар дәрәҗәсен һәм яшьләр арасында криминоген хәлне киметү;<br>- уку йортларында, хезмәт коллективларында, халыкның яшәү урыны буенча һәм хезмәт ияләренең массакүләм ял итү урыннарында спорт корылмалары челтәрен үстерү;<br>- гамәлдәге спорт матди базасын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру |
| Программаның билгеләнеше | - халыкның физик культура һәм спортны үстерүгә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шартлар тудыру;<br>- физик культура һәм спортны үстерү буенча учреждениеләр инфраструктурасын булдыру һәм киңәйтү;<br>- талантлы (сәләтле) балалар һәм яшьләргә ярдәм итү һәм үстерү системасын булдыру һәм тәэмин итү |
| Финанслау | Программаны финанслау чыганаклары булып төрле дәрәҗәдәге бюджетлар (федераль, республика, җирле), предприятие һәм оешмалар акчалары тора. Финанслауның гомуми күләме 132973,2 мең сум тәшкил итә.<br>Шул исәптән:<br>- җирле бюджеттан - 117802,50 мең сум,<br>- республика бюджетыннан - 12770,70 мең сум.<br>- бюджеттан тыш чаралар - 2 400,00 мең сум, шул исәптән еллар буенча:<br>2021 елда:<br>- җирле бюджеттан - 38 879,00 мең сум ,<br>- республика бюджетыннан - 5150,70 сум,<br>- бюджеттан тыш чаралар - 800,00 мең сум<br>2022 елда:<br>- җирле бюджеттан - 39 262,70 мең сум,<br>- республика бюджетыннан - 3759,00 сум,<br>- бюджеттан тыш чаралар - 800,00 мең сум<br>2023 елда:<br>- җирле бюджеттан - 39 660,80 мең сум,<br>- республика бюджетыннан - 3861,00 сум,<br>- бюджеттан тыш чаралар - 800,00 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә мөмкин |

| | |
|---|---|
| Программаның заказ бирүчесе | ТР Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Төп башкаручылар | - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге (алга таба - текст буенча - ЯЭСһТБ);<br>- «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе (алга таба-текст буенча-мәгариф бүлеге);<br>- Саба һәм Теләче районнары хәрби комиссариаты (килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы муниципаль районының җирле үзидарә органнары;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (алга таба - текст буенча- ТР ХХЭТИСЯМ СЯБ, килешү буенча);<br>- «Теләче үзәк район хастаханәсе» муниципаль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба - РҮХ, килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәдәният бүлеге (алга таба текст буенча - мәдәният бүлеге);<br>- «Татмедиа» ААҖ филиалы (килешү буенча) |
| Әлеге Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |

## 1. Кереш

Социаль-икътисади сәясәтнең мөһим өлеше булып физик культура һәм спортны нәтиҗәле үстерү тора.

Физик культура һәм спорт өлкәсе җәмгыятьтә күп функцияләр башкара һәм халыкның барлык яшь төркемнәрен үз эченә ала. Физик культура һәм спорт ул - кеше шәхесенең физик, эстетик һәм әхлакый сыйфатларын үстерү, иҗтимагый файдалы эшчәнлек оештыру, халыкның ялын оештыру, авыруларны профилактикалау, яшь буынны тәрбияләү.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, наркомания, эчкечелек, тәмәке тарту һәм хокук бозулар белән көрәштә физик культура һәм спорт чараларының нәтиҗәлелеге аеруча яшьләр арасында бик югары.

Шул уңайдан Теләче муниципаль районында барлык халыкка да, балалар һәм яшүсмерләргә дә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүнең даирәсен арттыру буенча эш алып барыла.

2021 елның 1 гыйнварына физик культура һәм спорт белән даими рәвештә шөгыльләнүчеләр саны 6244 кеше тәшкил иткән (район халкының 49,7%ы), шул исәптән:

1. Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә 1139 кеше («Теләче» спорт мәктәбендә – 426 кеше, «Юность» спорт мәктәбендә - 185 кеше (БСМҮ - 528 кеше). БЯСМ һәм БСМҮ шөгыльләнүче укучыларның чагыштырма күләме районның гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларының гомуми саныннан 89,56% тәшкил итә.

Көрәш, хоккей, шорт-трек, волейбол, футбол, баскетбол, чаңгы спорты, армспорт, өстәл теннисы, җиңел атлетика, билбау көрәше, бадминтон - спорт төрләре популяр.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә 63 штаттагы белгеч эшли, алар арасында мәктәп тренер- укытучылары, БСМҮ укытучылары, яшәү урыны буенча тренерлар да бар.

2. 21 физик культура коллективында район предприятиеләрендә, учреждениеләрендә һәм оешмаларында 3560 кеше шөгыльләнә, ягъни барлык эшләүчеләрнең 56,7 проценты.

3. Физик мөмкинлекләре чикләнгән физкультура белән шөгыльләнүче кешеләр – 458 кеше (район территориясендә яшәүче физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең 20%).

Бүгенге көндә районда 89 спорт корылмасы эшли, аларга 2188 кеше керә ала. Аларга керү барлык категория кешеләр өчен, көн саен ирекле.

2021 елда спорт заллары белән тәэмин ителеш 92,03 % тәшкил итә, спорт залларының гомуми саны – 18, 10 төзелгән һәм җайлаштырылган бина. Гомуми мәйданы-4543 кв. м.

Районда яссылык корылмалары белән тәэмин ителеш 2021 ел башына ике йөз процент тәшкил итә. Яссы корылмаларының гомуми мәйданы - 49893 м2.

Спорт корылмаларының бер тапкыр үткәрүчәнлеге - 129,6%.

## 2. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманы характерлау

«2021-2022 елларга Теләче муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» программасы спорт традицияләрен саклап калуны һәм үстерүне, халыкның барлык яшь категорияләре белән физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшенең массакүләм һәм индивидуаль рәвешләрен үстерү өчен шартлар булдыруны күздә тота.

Районда спорт-массакүләм һәм физкультура-сәламәтләндерү чараларын оештыру буенча зур эш алып барыла. 2021 елда 68 район һәм 24 республика һәм бөтенроссия спорт чараларында 1800 кеше катнашты.

Әмма район бюджеты акчаларының чикле булуы планлаштырылган чараларны тулысынча гамәлгә ашыруга комачаулый, бу киләчәктә спорт нәтиҗәләренә дә йогынты ясарга мөмкин. «Физик культура һәм спорт» статьясын финанслау расланган нормативлар нигезендә гамәлгә ашырыла. Акча физкультура-спорт чараларын үткәрүгә, зона, республика һәм Россия ярышларында катнашу өчен командировкага киткән чыгымнарга тотыла.

2018 елда яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенең бюджеты 182,0 мең сум, 2019, 2020 елларда – 182,8 мең сум тәшкил итте. Чынлыкта, планлаштырылган чараларны тулысынча үтәү өчен бүлеккә елына кимендә 3 млн.сум кирәк. Акчаны җәлеп итү, шул исәптән иганәчеләр ярдәме һәм грант ярдәме конкурсларында катнашу хисабына да планлаштырыла.

Соңгы елларда Теләче муниципаль районында спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгыту буенча эш алып барыла:

- Теләче авылында «Батыр» универсаль спорт залы файдалануга тапшырылды;
- «Теләче-Арена» ябык боз шугалагы,
- «Дулкын» ябык йөзү бассейны.

Районның 8 торак пунктында хоккей тартмалары төзелде (Шәдке, Олы Нырсы, Олы Мишә, Югары Кибәхуҗа, Кече Кибәхуҗа, Олы Мәтәскә авыллары.),

«Бердәм Россия» партиясе инициативасы буенча районда мини-футбол, волейбол, баскетбол һәм урам тренажерлары өчен 26 универсаль спорт мәйданчыгы төзелде һәм файдалануга тапшырылды.

Ел саен район гомуми белем бирү мәктәпләренең спорт залларында һәм спорт мәктәпләре балансында булган спорт корылмаларында косметик ремонт үткәрелә.

Ел саен, республика бюджеты хисабына, районның спорт мәктәпләре эшен оештыру өчен спорт җиһазлары һәм экипировка килә. Җирле бюджет хисабына хоккей формасы, районның гомуми белем бирү мәктәпләрен һәм спорт учреждениеләрен тәэмин итү өчен чаңгы комплектлары сатып алынган.

Һәр ведомство карамагындагы учреждениедә түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскуранты, шулай ук әлеге хезмәтләрне гражданнарның аерым категорияләренә: аз тәэмин ителгән һәм күп балалы гаиләләрдән булган балаларга һәм яшүсмерләргә, ятимнәргә, опекага алынган балаларга, инвалидларга, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә, КДН һәм ПДНда исәптә торучы балаларга һәм үсмерләргә ташламалар һәм түләүсез нигездә хезмәт күрсәтү кагыйдәләре расланды.

Шул ук вакытта районның физкультура-массакүләм эшен оештыруда кайбер җитешсезлекләр бар:

1. Чаңгы ярышлары, өстәл теннисы, футбол, волейбол кебек спорт төрләре буенча спортчыларның осталыгы акрын үсә.

2. Балалар бакчаларында физкультура-массакүләм эш начар оештырылган.

3. Районның күпчелек торак пунктлары спорт инвентаре һәм җиһазлары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәгән.

4. Адаптив физик культура һәм спорт өлкәсендә эш җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле оештырылмаган. Халыкның әлеге категориясе белән шөгыльләнүче тренерның штат берәмлеге юк.

Килеп туган хәлне анализлап, түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкин:

1. Районда физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чараларны оештыру һәм үткәрү системасы булдырылды.

2. Районның торак пунктларында физик культура һәм спорт белән матди-техник тәэмин ителеш яхшы хәлдә.

3. Өлкәннәр арасында физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүнең массалыгы һәм даими булуы, физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне системалы рәвештә спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү уртача дәрәҗәдә тора.

4. Авыл яшьләре белән яшәү урыны буенча физкультура-спорт эше начар оештырылган. Төрле юнәлештәге секцияләр ассортименты чикләнгән (уртача 2-3 секция).

5. «Физик культура һәм спорт» статьясын финанслау яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тарафыннан планлаштырылган чараларны үтәү өчен җитәрлек түгел.

Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге алдында физик культура һәм спорт өлкәсендә халыкның арта баручы ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен файдаланыла торган ресурсларның нәтиҗәлелеген арттыру бурычы тора.

Районда физик культура һәм спортны алга таба да нәтиҗәле үстерү өчен түбәндәгеләр кирәк:

1. Спортның перспектив төрләрен билгеләү.

2. Районда яңа, аеруча популяр һәм кирәкле спорт төрләрен кертү һәм үстерү (ирекле көрәш, фигуралы шуу, зур теннис, ат спорты, кул көрәше һ.б.).

3. Барлык спорт корылмаларының тулы йөкләнеше ведомство карамагына бәйсез рәвештә.

4. Яшенә һәм җенесенә карамастан, халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә максималь җәлеп итү. Шул исәптән ГТО ВФСК җәлеп итү юлы белән дә.

Әлеге Программа югарыда күрсәтелгән проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

## 3. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары һәм төп принциплары

Әлеге программаның максаты-халыкның барлык категорияләре арасында массакүләм физик культураны тотрыклы үстерүне тәэмин итү, халыкның сәламәтлеген ныгытуга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр санын арттыруга юнәлдерелгән нәтиҗәле чара буларак.

Максатка ирешү күрсәткечләре:

- физик культура белән даими шөгыльләнүче халыкның гомуми саныннан чагыштырма авырлыгы, %;

- республика һәм Россия чемпионатларында, беренчелекләрдә, кубокларда спортчылар яулаган призлы урыннар саны;

- республика һәм бөтенроссия җыелма командалары составына керүче спортчылар саны;

- даими рәвештә физик культура белән шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр саны;

- республика һәм бөтенроссия ярышларында җиңүчеләр һәм призерлар саны.

Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү хисабына мөмкин:

1. Спорт инфраструктурасын үстерү һәм функцияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

2. Балалар-яшүсмерләр спортын үстерү һәм спорт резервын әзерләү.

3. Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен адаптив физик культураны үстерү.

4. Халыкның барлык категорияләре арасында массакүләм спортны үстерү.

5. Спортның өстенлекле төрләрен үстерү, югары класслы спортчылар әзерләү өчен шартлар тудыру.

6. Халыкның даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә ихтыяҗын формалаштыру, халыкның сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

7. Физик культура һәм спорт буенча квалификацияле белгечләр җәлеп итү.

8. Физик культура һәм спорт өлкәсен фәнни, мәгълүмати-методик яктан тәэмин итү.

Әлеге программаны тормышка ашыру түбәндәге принципларга нигезләнергә тиеш:

1. Халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеге.

2. Халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре өчен физик тәрбия һәм белем бирү процессының өзлексез һәм дәвамчанлыгы.

3. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, мәгариф учреждениеләре, физик культура һәм спорт учреждениеләре, иҗтимагый оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләрнең физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләрендә үзара хезмәттәшлеге. Район предприятиеләре, оешмалары һәм авыл җирлекләре җитәкчеләре ягыннан ярдәм.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганаклары булып төрле дәрәҗәдәге бюджетлар (федераль, республика, җирле), предприятие һәм оешмалар акчалары тора. Финанслауның гомуми күләме 132973,20 мең сум тәшкил итә.

Шул исәптән:

- җирле бюджеттан - 117802,50 мең сум,

республика бюджетыннан - 12770,70 мең сум.

- бюджеттан тыш чаралар - 2400,00 мең сум, шул исәптән еллар буенча:

2021 елда:

- җирле бюджеттан - 38879,00 мең сум,
- республика бюджетыннан - 5150,70 сум,
- бюджеттан тыш чаралар - 800,00 мең сум

2022 елда:

- җирле бюджеттан - 39262,70 мең сум,
- республика бюджетыннан - 3759,00 сум,
- бюджеттан тыш чаралар - 800,00 мең сум

2023 елда:

- җирле бюджеттан - 39660,80 мең сум,

республика бюджетыннан - 3861,00 мең сум.

- бюджеттан тыш чаралар - 800,00 мең сум.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм ТР Теләче муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Теләче муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

## 5. Көтелгән нәтиҗәләр:

- Теләче муниципаль районында яшәүчеләрнең сәламәтлеген яхшырту, кешеләрнең гомер озынлыгын арттыру;
- яшьләр арасында җинаятьчелек, наркомания, эчкечелек дәрәҗәсенең киметү;
- физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнүчеләр саны арту. Систематик рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халыкның чагыштырма авырлыгы 2023 ел ахырына 45,4 %тан 50,5 %ка кадәр артачак;
- физкультура-массакүләм һәм спорт чаралары санын арттыру (2023 ел ахырына - 200 чарага кадәр, 8000 катнашучы);
- спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүчеләр санын 1350 кешегә кадәр арттыру;
- физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләр санын 70 кешегә кадәр арттыру.

## Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары (үлчәү берәмлекләре) | Индикаторлар әһәмияте (фараз) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
| Ел саен | Спорт объектлары саны, берәмлекләр | 89 | 77 | 77 | 77 | 77 |
| Ел саен | Халыкны спорт заллары белән тәэмин итү, % | 107,4 | 107,4 | 107,4 | 107,4 | 107,4 |
| Ел саен | Халыкны яссы спорт корылмалары белән тәэмин итү, % | 259,94 | 200,2 | 200,2 | 200,2 | 200,2 |
| Ел саен | Спорт билгеләнешендәге объектларның бер тапкыр үткәрүчәнлек сәләте, % | 136,8 | 129,6 | 129,6 | 129,6 | 129,6 |
| Ел саен | Спорт төрләре буенча секцияләрдә, төркемнәрдә һәм бүлекчәләрдә, физкультура-савыктыру юнәлешендәге төркемнәрдә, клубларда һәм үзәкләрдә даими шөгыльләнүчеләр, мең. кеше (район халкының гомуми санына карата процентлар) | 48,7 | 49,7 | 52,0 | 53,5 | 55,0 |
| Ел саен | Физик күнегүләр ярдәмендә үз сәламәтлегенә ярдәм итүче халык өлеше, % | 63 | 65 | 70 | 75 | 78 |
| Ел саен | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өлеше, % | 14 | 16 | 18 | 19 | 20 |

## «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» программасын гамәлгә ашыру чаралары

| № т/б | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Гамәлгә ашыру срогы | Сумма (мең сум) | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тренерлар, яшь белгечләр эшендә ярдәм күрсәтергә | «Теләче» СМ, «Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 49,8<br>50,0<br>50,0 | РБ<br>РБ<br>РБ |
| 2. | Ярышларда алган нәтиҗәләре өчен югары квалификацияле спортчылар әзерләү буенча тренерлар эшендә ярдәм итәргә | «Теләче» СМ, «Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 100,00<br>100,00<br>100,00 | РБ<br>РБ<br>РБ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3. | «Спорт мәктәбенең иң яхшы тренеры» конкурсын уздыру турында Нигезләмә эшләргә һәм аны үткәрүне тәэмин итәргә | «Теләче» СМ, «Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 18,0<br>20,0<br>22,0 | ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ |
| 4. | Югары һөнәри белемле белгечләр әзерләүне тәэмин итәргә. Идел буе ФКиС һәм ТДГПУ академияләрендә (ФКиС факультеты) уку өчен сайлап алу | СМ | Ел саен | - | - |
| 5. | Ел саен тренерларны квалификация күтәрү курсларына җибәрергә | СМ | График буенча | - | - |
| 6. | Спорт өлкәсендә эшләүчеләргә аттестация узу өчен документларны вакытында әзерләүне тәэмин итәргә | СМ | Ел саен | - | - |
| 7. | Спорт чараларының календарь планы нигезендә район спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрнең республика ярышларында катнашуын тәэмин итәргә | «Теләче» СМ, «Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 500,0<br>550,0<br>580,0 | ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ |
| 8. | Көрәш, билбау көрәше, йөзү, волейбол, кул көрәше, хоккей буенча спорт мәктәпләре командалары белән укыту-күнекмә җыеннары оештырырга | СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 60,0<br>65,0<br>68.0 | ҖБ, БТ<br>ҖБ, БТ<br>ҖБ, БТ |
| 9. | Белем бирү мәктәпләре спортчыларының физик үсешенә һәм физик әзерлегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү | СМ, РМБ | 2022 | - | - |
| 10. | Белем бирү учреждениеләренең физик тәрбия укытучыларының, инструктор-методистларның, спорт мәктәбе тренерларының, балалар һәм яшүсмерләр өчен спорт чараларын оештырганда уртак эшен тәэмин итәргә:<br>- методик берләшмәләр эшендә катнашу,<br>- семинарлар, конференцияләр, ачык дәресләр үткәрү | РМБ, СМ | Даими | - | - |
| 11. | Яңа секцияләр булдыру һәм булганнарын тулыландыру юлы белән спорт төрләре буенча шөгыльләнүчеләр санын арттыру | СМ | 2021-2023 | - | - |
| 12. | "Хезмәткә һәм оборонага әзер" Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә ашыру максатларында районның төрле яшьтәге халкы арасында чаралар оештыру һәм үткәрү | ЯЭһСБ | 2021<br>2022<br>2023 | 76,0<br>78,0<br>80,0 | ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ |
| 13. | Халыкны массакүләм спортка җәлеп итү максатыннан хезмәт коллективлары һәм авыл җирлекләре арасында ярышлар оештыру һәм үткәрү | ЯЭһСБ | 2021<br>2022<br>2023 | 33,0<br>36,0<br>38,0 | ҖБ, БТ<br>ҖБ, БТ<br>ҖБ, БТ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 14. | «Өченче яшь» пенсия яшендәге затлар арасында спорт чаралары санын арттыру | ЯЭhСБ, СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 10,0<br>12,0<br>14,0 | ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ |
| 15. | Сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән гражданнар өчен спорт-сәламәтләндерү чаралары, ярышлар оештыру һәм үткәрү | ЯЭhСБ, СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 35,0<br>37,0<br>40,0 | ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ |
| 16. | Башка районнар спортчыларына республика дәрәҗәсендә көндәшлек тудырырга сәләтле спорт резервын әзерләү һәм спортчыларны тәрбияләү эшен активлаштырырга | «Теләче» СМ,<br>«Юность» СМ | 2021-2023 | - | - |
| 17. | Муниципаль спорт мәктәпләренең спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында (А төркеме) Спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру | «Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | -<br>201,8<br>-<br>202,0<br>-<br>202,0 | ҖБ<br>РБ<br>ҖБ<br>РБ<br>ҖБ<br>РБ |
| 18. | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен җиһазлар, инвентарь һәм экипировка сатып алу | «Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | -<br>45,5<br>-<br>46,5<br>-<br>47,0 | ҖБ<br>РБ<br>ҖБ<br>РБ<br>ҖБ<br>РБ |
| | | «Теләче» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | -<br>153,6<br>-<br>160,5<br>-<br>162,0 | ҖБ<br>РБ<br>ҖБ<br>РБ<br>ҖБ<br>РБ |
| 19. | Район командаларының тармак республика спартакиадаларында катнашуын оештырырга (муниципаль хезмәткәрләр, мәгариф хезмәткәрләре, хокук саклау органнары хезмәткәрләре, газ сәнәгате хезмәткәрләре спартакиадасы һ. б.) | ЯЭhСБ | 2021<br>2022<br>2023 | 55,0<br>1500,00<br>58,0<br>60,0 | ҖБ<br>РБ<br>ҖБ<br>ҖБ |
| 20. | Спорт мәктәпләре балансында булган спорт корылмаларын даими рәвештә инвентарьлаштыру һәм кирәкле ремонтлау | «Теләче» СМ,<br>«Юность» СМ | Ел саен июнь | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 21. | Спорт инвентарьларын прокатка алу хезмәтен киңәйтү | «Теләче» СМ, «Юность» СМ | Ел саен | - | - |
| 22. | Районның спорт корылмаларында ремонт эшләренең перспектив планын эшләү | СМ, ЯЭСhТБ, инфраструктура үсеше бүлеге | 2023 | Чыгымнар сметасы буенча | ЖБ |
| 23. | Барлык эшләп килүче спорт учреждениеләрен дәрестән тыш вакытта тулы көчкә эшләтүне тәэмин итү | «Теләче» СМ, «Юность» СМ | даими | - | - |
| 24. | Физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен «Спорткластер» (чаңгы трассалары, парклар, велоюллар һ. б.) рекреацион зоналар булдыру. | Район Башкарма комитеты | 2021-2023 | Аерым сметалар буенча | РБ, МБ |
| 25. | Район торак пунктларында спорт мәйданчыклары төзү | Район Башкарма комитеты | 2021<br>2022<br>2023 | 3100,0<br>3200.0<br>3300,0 | РБ<br>РБ<br>РБ |
| 26. | Спорт корылмаларын карап тоту:<br>- «Батыр» универсаль спорт залы,<br>- «Дулкын» бассейны,<br>- «Теләче-Арена» ябык боз шугалагы | «Теләче» СМ, «Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 8000,0<br>8200,0<br>8400,0 | ЖБ<br>ЖБ<br>ЖБ |
| 27. | Ат-спорт манежы төзелешен тәмамлау | Район Башкарма комитеты | 2023 | Сметалар нигезендә | РБ<br>ЖБ |
| 28. | «Теләче» газетасында, Интернет челтәрендәТеләче муниципаль районы сайтында спорт чаралары анонсларын бастырып чыгаруны тәэмин итәргә | СМ, ЯЭСhТБ | Даими | - | - |
| 29. | Теләченең «Теләче» (Тюлячи) газетасында ярышларның нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны тәэмин итү | СМ, ЯЭСhТБ | Даими | - | - |
| 30. | Район газетасында һәм Теләче муниципаль районы сайтында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, физкультура һәм спортны үстерүгә юнәлдерелгән мәгълүматны даими рәвештә трансляцияләргә | СМ, ЯЭСhТБ | Даими | - | - |
| 31. | Халык арасында физик культура һәм спорт, сәламәт яшәү рәвеше һәм хәрәкәт активлыгы нигезләре, ата-аналарның үз балаларының сәламәтлеге өчен җаваплылыгы турында мәгълүмат тарату | СМ, РМБ, ЯЭСhТБ | Регуляр рәвештә массакүләм чаралар үткәрү | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | вакытында, ата-аналар җыелышлары нда | | |
| 32. | Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт юнәлешендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы төрле милек формасындагы структуралар һәм спорт төрләре буенча федерацияләр белән хезмәттәшлекне оештыру | ЯЭСhТБ, СМ | Даими | - | - |
| 33. | Спорт учреждениеләре эшчәнлеге | «Теләче» СМ,<br>«Юность» СМ | 2021<br>2022<br>2023 | 38004,0<br>38373,5<br>39567,4 | ҖБ<br>ҖБ<br>ҖБ |
| | БАРЛЫГЫ: | | 2021 | 5150,70<br>38879,00<br>800,00<br>**44829,70** | ТР бюджеты<br>МБ бюджеты<br>БТ |
| | | | 2022 | 3759,00<br>39262,70<br>800,00<br>**43821,70** | ТР бюджеты<br>МБ бюджеты<br>БТ |
| | | | 2023 | 3861,00<br>39660,80<br>800,00<br>**44321,80** | ТР бюджеты<br>МБ бюджеты<br>БТ |

Текстта кыскарулар (СМ - спорт мәктәпләре, ЯЭСhТБ - яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, РМБ - район мәгариф бүлеге, РБ - республика бюджеты, ҖБ - җирле бюджет, БТ - бюджеттан тыш чыганаклар).».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин